СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**31 март, 2026 ел** **№ 65**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 12 ноябрендәге 125 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль норматив хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы прокурорының протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2025 елның 20 маендагы 301/пр номерлы боерыгы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 12 ноябрендәге 125 номерлы карары (Советның 31.01.2022 № 143, 07.06.2023 № 301, 21.11.2023 № 348, 23.10.2024 № 456 карарлары редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаны яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә:

«Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль чаралар уздыру өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш.Шакиров

Биектау муниципаль районы
Советының 2026 елның
31 мартындагы 65 номерлы карарына
кушымта

**Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары**

1. Муниципаль контроль органына күпфатирлы йорттагы урыннар милекчесе булган граждан яисә оешманың, күпфатирлы йорттагы урыннардан файдаланучы булып торган гражданнарның мөрәҗәгате, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан контрольдә тотылган зат эшчәнлегендә аста саналганнарга карата түбәндәге мәҗбүри таләпләрдән бер генә булса да тайпылыш булу турында мәгълүмат керү:

а) күпфатирлы йортта торак урынны торак булмаган урынга һәм торак булмаган урынны торак урынга күчерүне гамәлгә ашыру тәртибенә;

б) күпфатирлы йортта урыннарны яңадан планлаштыру һәм (яисә) үзгәртеп кору тәртибенә;

в) күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә;

г) күпфатирлы йортлардагы урыннардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә;

д) авария-диспетчерлык хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру өлешендә күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затлар эшчәнлегенә;

е) йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларыннан файдаланганда һәм аларны карап тотканда куркынычсызлыкны тәэмин итүгә.

Әлеге индикаторның булуы закон белән саклана торган кыйммәтләргә турыдан-туры зыян (зарар) китерү куркынычы турында сөйли һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә кичекмәстән планнан тыш контроль чарасын үткәрү өчен нигез булып тора.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында Муниципаль контроль органына күпфатирлы йорттагы урыннар милекчесе булган граждан яисә оешманың, күпфатирлы йорттагы урыннан файдаланучы булып торган

гражданның мөрәҗәгате, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүмат керү, әлеге индикаторларның 1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдән һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясындагы 12 өлеше нигезендә планнан тыш контроль чарасын үткәрү өчен нигез булган мөрәҗәгатьләрдән тыш, әгәр әлеге мөрәҗәгать килгәнче бер ел дәвамында контрольдә тотылучы затка мәгълүмат муниципаль контроль органы тарафыннан шундый ук мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр игълан ителгән очракта.

3. Муниципаль контроль органы адресына Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында күпфатирлы йорттагы урыннар милекчесе булган гражданнар яисә оешмалардан, күпфатирлы йорттагы урыннан файдаланучы булып торган гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар санының алдагы шул ук чор һәм (яисә) алдагы календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда вакыт берәмлеге (ай, алты ай, унике ай) өчен ике тапкыр һәм аннан да артыгракка үсеше.

4. Күпфатирлы йорттагы урыннар милекчесе булган гражданнан яисә оешмадан, күпфатирлы йорттагы урыннан файдаланучы гражданнан алынган белешмәләрнең (мәгълүматның), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматның һәм торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында контрольдә тотылучы зат тарафыннан урнаштырылган мәгълүматның биштән артык туры килмәү фактын өч ай эчендә ачыклау.

5. Дәүләт торак күзәтчелеген яисә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы органда Россия Федерациясе арбитраж суды тарафыннан күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренә һәм алардан файдаланучыларга тиешле төрдәге коммуналь хезмәтләр күрсәтүне һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар сатып алуны тәэмин итү максатларында энергия белән тәэмин итү (сату-алу, электр энергиясе (егәрлек) китерү), җылылык белән тәэмин итү һәм (яисә) кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү, су чыгару, газ китерү (шул исәптән баллоннарда көнкүреш газы китерү) шартнамәсе (шартнамәләре) буенча, каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә шартнамә (шартнамәләр) буенча планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү һәм аның төрен сайлау турында карар кабул ителгән көнгә кадәр унике ай эчендә барлыкка килгән гомуми суммасы өч йөз мең сумнан артып киткән бурычны

түләтү турында дәгъва гаризасын (дәгъва гаризаларын) кабул итүе турында белешмәләр булуы.

6. Дәүләт торак күзәтчелеген яисә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы органда Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан расланган куллану нормативыннан чыгып, рәттән өч хисап чорыннан артыграк җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү исәпләү турында белешмәләр булуы.